ИПИЛЕ «ИПЛЕ»:

Карагуҗа ипиен халык яратып ала

> 2

ЯКТЫ КЕШЕ ИДЕ

Шагыйрә Фәйрүзә Мөслимова белән хушлашу

> 3

20 ЕЛЛЫК ТЫНЛЫК

Камал театрында – туганнар һәм милли сәясәт турында премьера

> 4



ФУТБОЛ КРИЗИСЫ:

«Рубин» ни өчен җиңелде?

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 162 (28744) | Сишәмбе | 9 ноябрь | 2021 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan @vatanymtatarstan /vatanimtatarstan

4604609 000131

БАШКА ЮЛ ЮК

ТАТАРСТАНДА КОРОНАВИРУС БЕЛӘН БӘЙЛЕ ЧИКЛӘҮЛӘР КАТГЫЙЛАНА

Көн кадагында

Тынычланырга хакыбыз юк! Торган саен үсә генә барган коронавируслы саннар бу сүзләрнең хаклыгын исбатлап тора. Соңгы бер тәүлек эчендә республикада коронавирус йоктыруның 239 (!) яңа очрагы теркәлде.

Вазгыять катлаулана бара. Шул сәбәпле республика җитәкчелеге коронавирус белән бәйле яңа чикләүләр кертергә мәҗбүр. Бу хакта Хөкүмәт йортында узган киңәшмәдә Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов хәбәр итте. Бүгеннән башлап республикада эш бирүчеләр коронавируска каршы беренче прививкасы ясалмаган хезмәткәрләрен эштән җибәрергә тиеш була. Республиканың Баш дәүләт санитар табибы карары бу. Әлеге яңалык соңгы алты ай эчендә коронавирус белән авырган һәм кулында ковидка каршы прививка ясатырга ярамаганлыгын дәлилләүче белешмәсе булган кешеләргә кагылмый.

Тагын ун көннән җәмәгать транспортында да QR-код буенча гына йөреп булачак. «Миңа җәмәгать транспортында битлек режимын бозу турында күпсанлы мөрәҗәгатьләр килә. Анда кеше бик күп бит. Аларны аерып та утырта алмыйсың. Син башка кеше өчен куркыныч тудырасың, моны аңларга кирәк», – диде Рөстәм Миңнеханов. Шуңа күрә тагын ун көннән җәмәгать транспортында QR-коды яки ковидка каршы прививка ясатырга ярамаганлыгын дәлилләүче белешмәсе булган кешеләр генә йөри алачак. Контрольдә тоту уңайлырак булсын өчен медотвод турындагы белешмәләр электрон форматка күчереләчәк. Президент республиканың Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгына шундый күрсәтмә бирде.

Коронавируска каршы прививка ясатырга ярамаганлыкны раслаучы әлеге электрон белешмә нидән гыйбарәт булачак? Бу сорауга ачыклык кертү өчен, министрлык белән элемтәгә кердек. Анда исә әлеге сорауга төгәл генә җавап бирмәделәр. «Бу мәсьәлә тикшерелә генә әле. Бу атнада шуңа кагылышлы киңәшмә узачак. Президентның күрсәтмәсе бар – чишелеш булачак», – дип белдерделәр «ВТ» хәбәрчесенә.

Ике елдан бирле тормышыбызны агулаган чирнең ни дәрәҗәдә мәкерлелегенә инану өчен, рәсми саннарга күз салу да җитә. Пандемия башланганнан бирле республикада 32 меңләп кеше коронавирус йоктырган, 1041 кешенең гомере өзелгән. 1 миллион 670 мең кешегә коронавируска каршы вакцинаның беренче компоненты ясалган. Республикада барлыгы 170 вакцинация пункты эшли. 60 яшьтән өлкәнрәкләр арасында вакцинация әле дә булса авырдан бара. Бу мәсьәләгә Рөстәм Миңнеханов та басым ясады. «Коронавирустан үлүчеләрнең 85 процентын өлкән яшьтәгеләр тәшкил итә. Бу – бик зур сан. Аларга яшисе дә яшисе иде бит әле. Аларның кайберләре вакцина ясатмаган, кемдер аны, киресенчә, соңрак ясатып, антитәнчекләр формалашырга өлгермәгән. Статистика бу. Мине тәнкыйтьли алалар, әмма без чаралар күрәчәкбез. Безнең башка юлыбыз юк», – дип белдерде Президент.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Республика җитәкчесе вакцинация дәрәҗәсенең студентлар арасында да түбән булуын искәртте. Һөнәри белем бирү оешмалары җитәкчеләренә мөрәҗәгать итеп, дәресләргә QR-код яки медотвод турында белешмәсе булган студентларны гына кертергә киңәш итте ул. Шулай ук Президент профессор-мөгаллимнәрне, уку йортларының барлык хезмәткәрләрен мәҗбүри вакцинацияләү турында да искәртте. «Гомер ул – иң кыйммәтлесе. Бер гомерне саклап калу да – зур казаныш. Бер кешене югалту да – безнең өчен бик зур фаҗига. Үз сәламәтлегеңне кайгыртырга, туганнарың, якыннарың, хезмәттәшләрең турында уйларга кирәк», – дип белдерде ул.

Сүз уңаеннан, бу көннәрдә Россиядә вакцинация турындагы сертификатның яңа формасы гамәлгә керде. Яңа документта прививка ясаткан кеше турында тулы мәгълүмат (исем-фамилиясе, әтисенең исеме, туган көне, җенесе, адресы һәм белешмә тутырылган дата) күрсәтелгән. Моннан тыш биредә QR-код, прививка датасы, вакцинаның атамасы да урын ала. Сертификатка ревакцинация, медицина каршылыкларының булу-булмавы һәм кешенең әлеге авыруны кичерүе турында мәгълүмат та кертеләчәк. Яңа формадагы электрон сертификат вакцина ясаткач өч көннән дә соңга калмыйча пәйда булачак. Моңа кадәр рәсмиләштерелгән барлык сертификатлар исә «Дәүләт хезмәтләре» порталында яңадан рәсмиләштереләчәк.

QR-кодның гамәлдә булу вакыты үзгәрми. Россия Сәламәтлек саклау министрлыгы белән Россия Цифрлы үсеш, элемтә һәм массакүләм коммуникацияләр министрлыгы ковидтан прививка ясаткач бирелә торган QR-кодның гамәлдә булу вакыты турындагы мәсьәләгә шулай дип ачыклык кертте. Билгеле булганча, кичә QR-кодның гамәлдә булу вакыты 12 айдан 6 айга кыскартылган дигән хәбәр таралган иде. «QR-кодның гамәлдә булу вакыты үзгәрми. Ковидтан прививка ясаткач, «Дәүләт хезмәтләре» порталында бирелә торган QR-код үз вакытында гамәлдә була. 8 ноябрь көнне иртән «Дәүләт хезмәтләре» порталын кулланучылар QR-кодның гамәлдә булу вакыты үзгәрүен абайлап алды. Бу порталда уза торган техник эшләр белән бәйле. Хәзер портал штатлы режимда эшли. QR-кодлар яңадан торгызыла», – диелә министрлык хәбәрендә.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Ялган QR-код өчен – җәза

Россия Сәламәтлек саклау министрлыгы коронавирустан вакцинация турында сертификатның рәсми документ булып торуы турында боерык чыгарган. Боерык кичә – 8 ноябрьдә үз көченә керде. Шуңа күрә прививка ясатмыйча гына ялган сертификат сатып алучыларны хәзер җинаять җаваплылыгы көтә. Татарстан буенча эчке эшләр министры урынбасары Алексей Соколов бу хакта кисәткән иде инде. «Ялган сертификат сатып алу, саклау яки аннан файдалану өчен «Ялган документ сатып алу, саклау, йөртү» статьясы нигезендә җәза чарасы күреләчәк. Бу статья буенча иң зур җәза – бер елга кадәр иректән мәхрүм итү», – диде ул.

Министр урынбасары әйтүенчә, ялган документтан файдаланучылар гына түгел, аны ясаучылар, шулай ук сатып алучылар, үзләре белән йөртүчеләр дә җинаять җаваплылыгына тартылачак.

Русчасыз булмый

Рус теленнән сынау барлык югары уку йортларына керү өчен, өстәвенә әле барлык белгечлекләр өчен мәҗбүригә әйләнә. Россия Фән һәм югары белем министрлыгы үзенең боерыгы белән бакалавриат, специалитет программалары буенча вузларга керүчеләр өчен сынаулар исемлеген раслаган. Исемлектәге математика фәне буенча сынау кайбер техник белгечлекләр өчен мәҗбүригә әйләнә. Информатика, физика, химия, чит тел, кирәк булганда, мәгариф оешмасы үзе билгеләячәк сынаулар исемлегенә кертелгән.

Министрлык боерыгы белән Хокукый мәгълүматлар рәсми порталында танышырга мөмкин. Документ киләсе елның 1 мартыннан үз көченә керә һәм 2027 елның 1 сентябренә кадәр гамәлдә була.

МФЦ ялсыз эшли

tatarstan.ru

Татарстанның Күпфункцияле үзәкләре ялсыз эшләүләрен дәвам итә. 30 октябрьдән 7 ноябрьгә кадәр республикада 93 меңнән артыграк кешегә хезмәт күрсәтелгән. Вакцинация турында сертификат алу өчен Россия «Дәүләт хезмәтләре» порталында теркәлергә теләүчеләр аеруча күп. Бигрәк тә 1 ноябрьдә бу уңайдан мөрәҗәгать итүчеләр ишле булган: барлыгы 8 меңнән күбрәк гариза тапшырылган. Гомумән алганда, бәйрәм көннәре – 4, 6 һәм 7 ноябрьдә республикада МФЦ филиаллары офисларына 7 меңнән артыграк кеше порталда теркәлү өчен мөрәҗәгать иткән.

Күпфункцияле үзәк директоры Ленара Мозаффарова әйтүенчә, якын араларда да порталда теркәлүгә ихтыяҗның зур булуы көтелә. Шуңа күрә МФЦ ялсыз эшләвен дәвам итә. Эш көннәрендә үзәк филиалларында порталда теркәү өчен өстәмә эш сәгатьләре күздә тотылган. Якшәмбе көнне исә биредә QR-кодлар гына бирелә.

Актуаль тема

Ятып калганчы, әйтеп кал

Бөтенроссия халык санын алуда онлайн рәвештә 14 ноябрьгә кадәр катнашып була. Ягъни җанисәптә катнашуның әлеге ысулы тагын бер атнага озайтылган. Аңа кадәр «Госуслуги РФ» порталы аша җанисәптә 8 ноябрьгә кадәр генә катнашып булуы хәбәр ителгән иде.

Ун елга бер килә торган илкүләм халык санын алуның соңгы көннәренваклыйбыз. Билгеле булганча, башка еллардан аермалы буларак, быелгы халык санын алуда «Дәүләт хезмәтләре» порталы аша онлайн рәвештә дә катнашып була. Ил халкының яртысы диярлек (46 процент) мондый мөмкинлек тудырылудан канәгать икән. Күптән түгел «Иҗтимагый фикер» фонды тарафыннан уздырылган сораштыру нәтиҗәләре шуны күрсәткән. Сораштыруда катнашучыларның тагын 36 проценты сан алучыларны өйдә көтүне кулайрак күрүен, 9 проценты исәпкә алу участокларына барырга җыенуларын әйткән. Соңгылары арасында өлкән яшьтәгеләр күбрәк икән. Яшьләр исә җанисәптә онлайн рәвештә катнашуга өстенлек бирә. «Респондентларның 75 проценты җанисәпне үткәрергә кирәк дигән фикердә тора. Бу – фонд моңа кадәр Бөтенроссия халык санын алу кампаниясенә багышлап үткәргән сораштыруга караганда күбрәк. Һәр яшь категориясендә сораштыруда катнашучыларның, шул исәптән 18–30 яшьтәгеләрнең күпчелеге җанисәптә катнашуны һәркемнең бурычы дип саный», – диелә фонд хәбәрендә.

Хәтерләсәгез, Татарстанда стационар участокларга барып тавыш бирүчеләр арасында 28 данә iPhone 13 телефоны уйнатырга вәгъдә иткәннәр иде. Яңа айфон ияләре «ВКонтакте» социаль челтәрендәге «Народный Татарстан» төркемендә узучы онлайн фотобәйге кысасында ачыклана. Бәйгедә 14 яше тулган, теләге булган һәркем катнаша ала. Моның өчен халык санын алу пунктларындагы баннер яки җанисәп турындагы плакат фонында төшкән фотоны #ТатарстанВместе #МояПерепись хэштегы белән «ВКонтакте» яки Instagram социаль челтәрләренә урнаштырырга гына кирәк. «ВКонтакте» челтәрендәге «Народный Татарстан» төркеме туры эфирында 14 ноябрьгә кадәр көн саен 20.00 сәгатьтә фотобәйгедә катнашучылар арасында икешәр җиңүче сайлап алына. Казанда, Әгерҗе, Чистай, Алабуга, Түбән Кама һәм Нурлат районнарында яшәүче 12 кеше бүләкне откан инде. Әле бу көннәрдә генә тагын ике айфонның иясе билгеле булды. Чираттагы ике айфонны Булат Мостафин һәм үзен Марат абый дип таныштырган бер егет откан. Җанисәп тәмамланганчы, оештыручылар тагын 16 смартфон уйнатырга җыена.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Татармын! Горурмын!

Әзһәр ШАКИРОВ, Россиянең һәм Татарстанның халык артисты:

Татар талантларга бай ул. Кайсы гына театрны алма, Россиянекеме ул, чит илдәме – иң төп рольләрдә татарлар уйный. Татар милләте нинди генә театрны туендырмый. Ул турыда уйлаган кеше бармы? Талантлы татар баласы рус мәдәниятенә күчә икән, минем өчен бәхетсезлек менә шушы. Талантларны саклап калу өчен, кулдан килгәннең бөтенесен эшләргә кирәк.

ТАТАРСТАНДА – ТУКЛАНУ

Татарстанстат белгечләре республикада яшәүчеләрнең 2019 һәм 2020 елларда нинди ризыкны күпме ашаганын исәпләп чыгарган. Инфографикада җан башына туры килгән саннар китерелә.



Суыта

Синоптиклар фаразына караганда, бу атнада көндезге һава температурасы 0 градус һәм аннан да түбәнрәк булачак, яңгыр, җепшек кар көтелә. Бүген Татарстанның күпчелек районнарында яңгыр, кичен – җепшек кар, төнлә секундына 15–18 метр тизлектә көчле җил. Көндез – +3...+8, төнлә +1...+6 градус җылы. Иртәгә дә республикада шундый ук һава торышы саклана. Көндез яңгыр, төнлә җепшек кар булырга мөмкин. Әмма суыта: төнлә терекөмеш баганасы – 1...–6, көндез 0...–4 градус күрсәтәчәк. Пәнҗешәмбе иртән һәм төнлә тагын да ныграк суытачак: – 4...–9 градус. Көндез көнбатыш районнарда җепшек кар явып үтәчәк. Көндезге һава температурасы +1...–4 градус чикләрендә тирбәләчәк.

Гидрометеоүзәкнең башлангыч фаразына караганда, җомга һәм шимбә көннәрендә Татарстанда урыны белән кар көтелә. Төнлә һава температурасы 0...–5, көндез +1...–2 градус булачак.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

ДОЛЛАР СТАНОГЫ ТУКТАРМЫ?

Ноябрь башында дөнья вакыйгалары 2020 елда салынган эздән баруларын дәвам итте: ил башкалаларында һәм зур шәһәрләрдә протест гадәти хәлгә әйләнде, энергетик кризис һаман да дәүләтләрне зур куркыныч астында тота, барлык базарларда да инфляция гиперинфляциягә әверелү белән яный. Илләр арасында конфликтлар көчәя, террор очраклары арта. Үткән якшәмбегә каршы төндә Гыйрак Премьер-министрына дрон ярдәмендә һөҗүм ясалды. Бу исә террорның яңа технологияләр этабына чыгуын күрсәтә. Багдадның иң нык сакланган «яшел зонасы»на үтеп кергән камикадзе-дрон хөкүмәт башлыгы резиденциясендә шартлау ясады, Премьер-министрның сакчылары яраланды, Мостафа Әль-Кадими үзе зыян күрмәде.

Алжир белән Марокко арасында сугыш куркынычы туды. Чүлдә ерак арага йөрүче өч алжирлы машина йөртүче шартлатып үтерелде. Ил Президенты Габделмәҗид Теббун бу үлемнәрдә Марокконы гаепләде һәм җавап бирү белән янады. Төрек дроннары һәм Көнбатыш коралы белән коралланган Марокко гаскәрләре белән Россия техникасын җиккән Алжир армиясе үзара көч сынашырга ихтимал. Әлегә конфликт «туңдырылган» хәлдә. Эфиопиядә коралны гыйсъянчылар хөкүмәт гаскәрләрен тар-мар итү алдында. Дөньяның башка почмакларында да кораллы конфликтлар куркынычы арта. Боларның барысының да «кендеге» финанс-икътисад кризисына бәйләнгән, әлбәттә. Сугыш бәяләр күтәрелү һәм бөлгенлек шартларында халыкларның игътибарын читкә юнәлтү өчен оештырыла.

Американың финанс аналитиклары арасында илдә гиперинфляция башланачагы турында хәбәр салучылар бар. Бәяләрнең бәйдән ычкынуының сәбәбе гади: Америка банкы – ФРС гадәттән тыш күп акча басты. Хәзер финанс җитәкчелеге ил базарын һәм дөнья икътисадын чүпләгән долларларны кире җыеп алмакчы. Соңгы ел ярым эчендә акча станогы 4,4 триллион доллар басып, базарларны тутырган иде. Бу – тарихи рекорд, аның кадәр кәгазь акчаның финанс базарына кыска вакыт эчендә ыргытылуын дөнья икътисады хәтерләми. Ноябрьдән башлап ФРС ай саен беркемгә дә кирәкмәгән әҗәт кәгазьләрен сатып алуны 15 миллиард долларга киметә башларга җыена. Шул темплар белән барып, киләсе елның июнендә доллар станогы берни белән дә тәэмин ителмәгән доллар басуны туктатырга ниятли. Мондый ниятләр элегрәк тә бар иде. Бу – уңай күренеш үзе. Әмма доллар басуны киметүгә, финанс базарындагы куыклар шиңә башлый да зур финанс түнтәрелеше куркынычы туа. Облигацияләр һәм акцияләрнең бәясе түбәнгә оча, спекулянтлар бөлә. Ай саен дистәләгән миллиард долларга баеган олигархлар катлавы байлыкларын югалта. Куллану товарларының бәяләре үсешен туктатырга һәм хәтта түбәнәя башларга да мөмкин. Икътисад классик кризиска әйләнеп кайта андый очракта. Әмма эшсезлек көчәя, кесәләрдә акча бетә. Доллар курсы ныгый, билгеле. Тик ул ныгу башка базарларда бәя үсешен китереп чыгара. Менә шундый вазгыятькә янкилар түзә алырмы, билгесез. Акча бассаң, базарлар җимерелә, туктатсаң – янә җимерелә. Икътисад шундый хәлдә хәзер. Шахматтагы «пат» вазгыятеннән чыгып булырга охшамаган. Тупиктан чыга алмаганда, сугыш сценарие запаста тора.

Россиядә

СӨТ БӘЯСЕМЕ, СӨТ БӘЛАСЕМЕ?

Сөткә бәя кибет киштәләрендәге инфляция биюенә үз өлешен кертергә җыена. Шикәргә, ярмаларга, үсемлек маена бәяләрнең рекордлы үсеше янәшәсендә сөт әлегә кадәр үзен тыныч тоткан иде. Дөресен генә әйткәндә, соңгы ун ел эчендә төп ризыкларның берсе булган бу продуктның бәясе үзгәрмәде диярлек. Мотор бәяләре ашкын маршта булды, сәнәгать товарлары хакы күккә чөелде, фуражлык ашлык бәясе ун ел элеккегедән дүрт тапкыр диярлек артты, хәтта ул биеклектән дә узып бара. Әмма авыл хуҗалыгына төп табыш китерү сәләтенә ия булган сөт бәясе кысадан чыга алмый, чөнки зур сәясәт белән билгеләнә. Былтыгы җәй сөт җитештерүчеләрне дилемма алдына куйды: я бәягә сумнар өстисең дә бөлгенлектән котыласың, я сыерларны бугазлап исән каласың. Әлегә акрын гына икенче вариант тормышка ашырыла. «Исән калу» дигәне – шартлы сүз генә, баш санын киметү – һәлакәтле вариант, ахыр чиктә ул дефицит һәм бәя күтәрелешен китереп чыгара. Россия Авыл хуҗалыгы министрлыгы сөткә бәяләр үсешен вәгъдә итә. Министрлыкның эчке докладында сөт бәясе еллык үсешенең башка азык-төлек инфляциясеннән калышуы турында әйтелә. 1 ноябрьгә ул – 7,28 процентка, атланмай 7,49 процентка гына үскән, ә Росстатның азык-төлек кәрҗине 10,91 процентка кыйммәтләнгән. Сөт бәясе дигәндә сүз авылдан сатып алу хакы турында түгел, ә кибет киштәсендәге саннар турында бара. Сатып алу бәясе дә берникадәр артты, әлбәттә, әмма терлек азыгы бәясе үсешен капларлык ук түгел. Авыл хуҗалыгы министрлыгы: «Җитештерүчеләр сөт бәясен үз табышларын югалту хисабына гына тотып торалар», – дип белдерә. Бер нәрсәгә игътибар итик: җитештерүче дигәндә сөтне аертып-сыеклап сатучылар, ягъни сөт заводлары турында сүз бара. Ә сыердан сөт савучы тармак чимал белән тәэмин итүче дип кенә санала. Төп югалтулар менә шул «чимал» тармагында булса да, «җитештерүчеләр» ныграк кычкыра һәм юрганны үз якларына таба ныграк тарта.

«Союзмолоко» оешмасы «җитештерүчеләр»дә сөтнең үзкыйммәте 10–12 процентка, аерым очракларда 27 процентка кадәр артуны белдерә. «Чимал» тармагының югалтулары турында сүз әйтелми, әмма ике тармакның да табышы кимү, хәтта зыянга эшләүчеләр дә күп икәнлеге искәртелә. Рәсми рәвештә ел башыннан сөт сатып алу бәяләренең 10–15 процентка үсүе таныла, шуңа ел ахырына кадәр тагын 5 процент өстәлер дип көтелә. Сүз кибетләрнең сатып алу бәясе турында бара. Еллык сөт инфляциясе 12,6 процент булыр дип әйтәләр. Бу күпме, азмы? Чагыштырыйк: Икътисади үсеш министрлыгы мәгълүматлары, үткән елның 1 ноябре белән чагыштырганда, йомырканың – 28,1 процентка, тавык итенең – 30,95 процентка, кыярның – 64,79 процентка, бәрәңгенең – 76,41 процентка, кәбестәнең 89,8 процентка кыйммәтләнүен әйтәләр. Бәяләр үсеше чәчләрне үрә торгыза торган, билгеле. Пенсионерлар нишләргә тиеш, аз керемле бюджеттагылар ничек очны очка ялгасын? Сораулар ачык кала. Әмма сыер асраучы авыл да, фуражның килосын 18–20 сумнан алып, хәзерге бәяләрдәге сөтне бүтән җитештерә алмый инде, монысы да хак.

ПРЕЗИДЕНТ КӨНДӘЛЕГЕ

tatarstan.ru

Казан югары танк команда училищесы полигонында Россия, Беларусь, Казахстан, Кыргызстан, Таҗикстан һәм Әрмәнстан хәрбиләре җыелды. Биредә Коллектив иминлек турындагы килешү оешмасы (ОДКБ) тынычлык урнаштыру көчләренең «Нерушимое братство – 2021» уртак өйрәнүе башланды.

Әлеге чараны ачу тантанасында Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов, Үзәк хәрби округ гаскәрләре командующие генерал-полковник Александр Лапин, ОДКБның берләштерелгән штабы башлыгы генерал-полковник Анатолий Сидоров катнашты.

Рөстәм Миңнеханов өйрәнүләр уздыру урыны итеп Татарстанны сайлаганнары өчен Россиянең Оборона министрлыгына рәхмәт әйтте. «Безнең өчен зур җаваплылык бу. Бүгенге халыкара вазгыятьтә дәүләтләребезнең барлык казанышлары ышанычлы рәвештә сакланырга тиеш. Өйрәнү барышында командирлар һәм солдатларның осталыгы камилләшер, ОДКБ тынычлык урнаштыру көчләрен заманча куллануда яңа алымнар барлыкка килер дип өметләнәм», – диде ул.

Өйрәнүдә ОДКБга кергән илләрнең кораллы көчләре һәм хокук саклау органнарыннан 1,8 мең кеше катнаша. Әлеге чарада 8 Ми-8 һәм Ми-24 вертолеты, ике Су-34 күпфункцияле истребителе-бомбардировщигы һәм башка төрдәге хәрби техникадан файдаланалар. Өйрәнү 12 ноябрьгә кадәр дәвам итәчәк.

* * *

Татарстан Конституциясе көнендә, Казанда муниципаль берәмлекләр арасында уздырылган республика бәйгесендә җиңүчеләр бүләкләнде. Район һәм шәһәрләргә 7 микроавтобус һәм 93 автомобиль тапшырдылар.

«Муниципаль җирлекләргә һәрвакыт ярдәм итеп киләбез, бу инде күркәм традициягә әверелде, – диде Президент Рөстәм Миңнеханов тантанада. – Соңгы елларда без 2,5 меңнән артык автомобиль тапшырдык. Муниципалитетлар – безнең таянычыбыз. Без сезнең белән тыгыз элемтәдә торабыз. Сез һәрвакыт хәрәкәттә булырга һәм вакытында чарасын күрә алырга тиеш. Авыр хезмәтегез өчен рәхмәт».

Әлеге бәйге 2010 елдан башлап уздырыла. Максаты – муниципаль берәмлекләрнең эш нәтиҗәлелеген арттыру, авыл һәм шәһәр җирлекләрендә халыкның тормыш сыйфатын яхшырту.

* * *

Рөстәм Миңнеханов Халыкара волейбол федерациясе (FIVB) техник директоры Стивен Таттон белән очрашты.

Очрашуда 2022 елгы Волейбол буенча дөнья чемпионаты матчларына әзерлек турында фикер алыштылар. Дөнья чемпионаты Россиядә 2022 елның 26 августыннан 11 сентябренә кадәр узачак. Уеннар илнең 11 каласында булачак. Казанда икенче төркем этабының 6 уены булачак.

УКЫТУЧЫСЫЗ ДӘРЕС

9 ноябрьдән коронавирустан прививка ясатмаган укытучылар мәктәпкә бара алмый. Әйтик, Түбән Камада 13 педагогка өйдә утырырга туры киләчәк. Без мәгариф оешмаларында коронавируска бәйле вазгыятьне белештек.

Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгының матбугат үзәгеннән алынган мәгълүматларга караганда, хәзерге вакытта ковид белән 28 укучы авырый. Ел башыннан барлыгы 60 бала чирләгән.

Түбән Камада коронавируска каршы прививка ясатудан баш тарткан 13 укытучы эштән читләштереләчәк. Бу хакта «эшлекле дүшәмбе»дә мәгариф идарәсе башлыгы Рамил Гыйниятуллин хәбәр иткән. Аның әйтүенчә, әлеге педагогларның дәресләре башка укытучылар арасында бүленәчәк. Шәһәрдә мәгариф өлкәсендә 57 хезмәткәр эштән читләштерелсә, 368енең медицина белешмәсе бар.

– Укуда кыенлыклар булмасын өчен үтенечем бар. Балалар газап чигәргә тиеш түгел. Без читтән торып укытып карадык инде. Балалар мәктәпләрдә булырга тиеш, – диде Түбән Кама районы башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы Рамил Муллин.

Биектауда барлыгы 966 укытучы, гомумән 1733 мәгариф хезмәткәре исәпләнә.

– Бездә барлык укытучылар, хезмәткәрләр дә вакцина ясатты. Биш процентының исә белешмәсе бар. Барлыгы 6700 бала белем ала. Каникулга кадәр 300 бала салкын тидереп чирләгән иде. Ковид белән авыручылар юк. 3200дән артык укучы грипптан прививка кадатты, – диде Биектау районы мәгариф идарәсе башлыгы Нияз Әхмәтҗанов.

Арча районының Яңа Кенәр мәктәбенә шалтыратып та вазгыять турында кызыксындык. Монда 301 бала укый.

– Октябрь ахырында директор вазыйфасыннан авыл җирлегенә эшкә күчтем. Каникулдан соң балаларның барысы да мәктәпкә килде дигән мәгълүмат бар. Арада суык тидергән берничә бала булса да, ковид белән чирләүчеләр юк. Барлыгы 40 укытучы белем бирә. Барлык хезмәткәрләр саны 60тан артык. Мин эштән киткәнче үк барысы да прививка ясатып бетерде. Кайберләренең медицина белешмәсе бар. Мәктәпкә укытырга кертелмичә калган укытучы булмаячак, – диде Яңа Кенәр авыл җирлеге башлыгы, элеккеге директор Әгъзам Гайфуллин.

Әгерҗе районы мәгариф идарәсендә, ковид белән авыручы укытучылар да, укучылар да юк, дигән яхшы хәбәр җиткерделәр. Укытучыларның да барысы прививкалы.

Казан мәктәпләрендә дә кайбер укытучылар дәрескә бара алмаячак.

– Бүген – каникулдан соң беренче көн. Әти-әниләре авырып, балалары килмәүчеләр бар. Бездә меңнән артык бала укый. Бер-ике бала гына авырый. Прививка ясатмаган укытучылар берничә, алар мәктәпкә кертелмәячәк. Өйләрендә укытачакмы, ул мәсьәләне әлегә хәл итеп бетермәдек, – диде Казандагы 16 нчы гимназия директор урынбасары Алсу Шакирова.

Хәзерге вакытта студентларның 32,2 проценты прививка ясаткан. Бер ай эчендә бу сан 11,2 процентка арткан. Ясатмаганнарга читтән торып укытуга күчәргә туры килмәсме?

Казан дәүләт архитектура-төзелеш университеты ректоры Рәшит Низамовның да фикерен белештек.

– Хәзерге вакытта QR-код кертү мәсьәләсен карыйбыз. Тик аларны тикшерү өчен дә кешеләр кирәк. Кемнеке юк, аларга читтән торып укырга туры киләчәк. Хәзерге вакытта студентларның 60 проценты вакцина ясатты. Башкалар да каршы түгел. Бу бары оешып җитмәүгә генә бәйле. Кайберләренең медицина белешмәләре бар. Онлайн форматта оештырылган дәресләр дә бар. Практик, лаборатор эшләр вузда үткәрелә. Уку катнаш формада уза. Дөнья ничек кылана, без дә шулай, – диде Рәшит Низамов.

Сәрия МИФТАХОВА



Илдар Мөхәммәтҗанов

ИПЛЕ ЭШ

Эшмәкәрлек

Тырыш, булдыклы кешеләргә авылда да эшмәкәрлек белән шөгыльләнер өчен мөмкинлекләр аз түгел. Яшел Үзән районының Карагуҗа авылында «Ипле» ипи пешерү цехы – әнә шуның ачык мисалы. Биредә берничә төрле ипи, күмәч, сохари, чәкчәк, кош теле, кекс һәм башка тәм-томнар пешереп саталар. Ризыклары тәмле, ихтыяҗ зур. Ашлы халыкның эше дә бар, димәк. Бүгенге тормышта анысы тагын да кадерлерәк.

Ипи пешерү мини-цехы директоры Дамир Подмарёв әйтүенчә, ризыкларны Яшел Үзән районы буенча тараталар. Шулай ук тәм-томнар Казанга да китә.

– Без базарга «Ипле» бренды белән кергән идек. Тора-бара цехның атамасын шулай ук калдырдык. Тик халык безне хәзер күбрәк «Карагуҗа ипие» дип белә. Әлеге вакытта халыктан килгән фикерләр, бәядән бик канәгать. Инде алар да безнең брендны танып, кибеттән нәкъ безнең ипине сорап алалар, – ди эшмәкәр.

Шушы еллар эчендә халыкның нәрсә яратуын яхшы белеп бетергән инде алар. Бодай һәм арыш ипиләре, батон – авыл халкының гына түгел, шәһәрдә яшәүчеләрнең дә еш һәм яратып ала торган ризыклары.

– Халык ипинең сыйфатына бик игътибар итә, – ди эшмәкәр. – Сортларын үзгәртмәсәләр дә, сыйфатка карап алалар. Аз гына хилафлык булса да, сүзе тиз килеп ирешә.

Яңа төрле ризыклар пешерсәләр дә, Дамир Подмарёв әйтүенчә, халык бер ияләшкәненә өстенлек бирә.

– Халык «Сельский», «Украинский», ак ипи алырга күнеккән икән, алар гел шуны гына ашаячак. Яңа ризыкка ияләштерү җиңел түгел. Ләкин без барыбер ассортиментны төрләндереп тору яклы. Шулай да берникадәр вакыт халыкта кызыксыну күрмибез икән, аны пешерүдән туктыйбыз, – ди ул.

Шундый яңалыклар буларак, күптән түгел генә цехта чүпрәсез ипи җитештерә башлаганнар. Шулай ук чәй эчәр өчен тәм-томнарны да төрләндереп торырга тырышалар.

Цехта бер тәүлек эчендә 3 мең тонна ризык әзерләнә.

– Кайбер цехлар тәүлек буе эшли, тик без башка юлны сайладык, чөнки тәүлек буе эшләү ипинең сыйфатына йогынты ясый. Заводларга шулай эшләү уңайлы, чөнки алар гадәттә зур шәһәрләрдә, район үзәкләрендә урнашкан. Пешергән ризыкны алып чыгып сата алалар. Без алай эшли алмыйбыз. Алдан күпме ипи, башка төр ризыклар пешерәсен исәпләп чыгарабыз да, төнлә шуны әзерлибез. Иртә белән таратып чыгабыз. Кичен бу цикл тагын кабатлана, – дип аңлата Дамир Подмарёв.

Билгеле булганча, соңгы вакытта чимал бәяләре бик нык артты. Шуңа бәйле рәвештә, цехка да авырлык төшә. Җитәкче фикеренчә, чимал бәясе күтәрелсә дә, халык кыйммәтле ипи алырга әзер түгел.

– Төп авырлык әнә шунда безнең, – ди ул. – Язын чимал бәяләре кинәт өскә сикергәч, апрельдә ипи бәясен бераз арттырдык. Көзен кабат шул хәл кабатланды. Октябрьдә бәяләрне күтәрмәкче идек, тик әлегә сабыр итеп торабыз. Чөнки халыкка болай да авыр икәнлеген күрәбез.

Директор әйтүенчә, бәяләр артуга халык кына түгел, җитештерүчеләр үзләре дә гаҗәпләнә һәм үзгәрешләрне алдан фаразларга өлгерми дә кала.

– Хәзер чимал белән тәэмин итүчеләр дә җиңел юлга басты, – ди бу җәһәттән Дамир Подмарёв. – Берничә ел элек алар, алдан шалтыратып, яки хатлар җибәреп, он бәясе арту турында кисәтә торганнар иде. Хәзер: «Он менә шундый бәягә артты. Бүген аласызмы? Иртәгә тагын шуның кадәрле артачак. Алсагыз, бүген аласыз…» – дип, кыен хәлгә куя. Ә безнең сайлау мөмкинлеге юк. Нәтиҗәдә без дә ипи бәясен күтәрергә мәҗбүр булабыз. Ел башыннан 7 процентка арттырдык. Тагын да югары бәя куя алмыйбыз, чөнки халык бик зарлана. Без шулай ук сыйфатка да зыян китерә алмыйбыз. Начар ипи пешерсәк, кыйммәтле бәягә аны тәгаен беркем дә сатып алмаячак. Шушы эшләү тәҗрибәсендә бер нәрсәгә инандык: халык ипи, батонга кагылышлы һәр үзгәрешкә бик нык игътибар итә һәм мөнәсәбәтен белдерә. Шуңа күрә безнең төп бурыч – ипине сыйфатлы итеп пешерү!

Карагуҗа авылындагы цехта 17 кеше эшли. Күпчелеге – шушы авыл кешеләре.

– Эшчеләребезне хезмәт хаклары тулысынча канәгатьләндерә дип әйтеп булмый. Чөнки алар бит кибеттәге бәяләрнең ничек үскәнен күреп тора. Ләкин безнең, аларга карап, хезмәт хакларын арттыру мөмкинлегебез юк, – ди җитәкче.

Зөһрә САДЫЙКОВА

АК КҮҢЕЛЛЕ КЕШЕ ИДЕ

Хушлашу

Татар халкының моңлы, җырлы кызы Фәйрүзә Мөслимова, безне ятим итеп, бакыйлыкка китеп барды. Коронавирус аркасында үпкәләре 90 процент зарарланган булган. Туганнары әйтүенчә, операциядән соң ясалма комадан чыга алмаган.

Без, «Ватаным Татарстан» газетасында эшләүчеләр, Фәйрүзә апаның хәле турында гел белешеп тордык. Хәләл җефете Камил абый Сәгъдәтшин редакциядә күренүгә, сүзебез Фәйрүзә апага барып тоташты. Тик соңгы көннәрдә күңел юатырлык сүзләр генә ишетә алмадык. Хәер, моны Камил абыйның халәтен күрүгә үк сиземләп була иде. Ике көн кала ул безгә йөрәкләрне өшетерлек сүзләр җиткерде. «Табиблар өмет юк дип әйттеләр. Бәхилләшеп чыктык».

Фәйрүзә апаны беренче күрүем дә Камил абый белән бәйле. Университетта укый башлаган көннәр иде. Бервакыт шулай баскычтан төшеп барганда, пышылдаша башладылар: «Әнә-әнә, Фәйрүзә Мөслимова белән Камил Сәгъдәтшин басып тора». Мин икесен дә белмим булып чыкты. Сораша торгач, аларның инде каләмнәре шактый чарланган, шигырьләр язып сөендергән студентлар булуын белдем. Бер факультетта укыгач, газета-журнал редакцияләрендә йөргәч, Фәйрүзә апа белән гел очрашкалап тордык. Бик тә якыннан танышуым, мөгаен, Пермь өлкәсенең Барда районында Татарстан көннәрен үткәргәндә булгандыр. Беренче чиратта ул мине татар хатын-кызларына хас сыйфатлар – тыйнаклыгы, сабырлыгы белән сокландырды. Шигырьләрен дә, бөтен игътибарымны биреп, нәкъ менә шунда, ул халык алдында чыгыш ясаганда тыңладым бугай. Һәр сүзеннән, һәр юлыннан самимилек, садәлек бөркелеп тора. «Мин!» дип, бер җиргә дә атылып, бәрелеп чыкмас, кеше күзенә күренергә тырышып йөрмәс. Әмма нәкъ менә шушы матур сыйфатлары аны биеклеккә күтәрә, яраттыра белә…

Туганнары, якыннары Фәйрүзә апа хакында: «Аның иманында һәркемгә сыенып өчен урын бар иде», – диләр. Моны туры мәгънәдә дә аңларга була. Ул укыган вакытларда ук гарәп теле дәресләренә йөри. Эчке дөньясы, йөрәге белән дингә тартыла. Күңел киңлеге дип карасак, бу аның эш-гамәлләрендә дә чагыла. Фәйрүзә апа озак еллар балалар «арба»сын тартып бара: «Ялкын» журналында эшли. Ничә буынны һәм никадәр баланы тәрбияләгән, канатлар куйган, кирәк урында, кисәтеп, башка якка борып җибәрә белгән, эчтән генә һәрберсе өчен көеп яшәгән кеше ул. Димәк, аны белмәгән татар журналисты юктыр диярга дә була. Шул ук вакытта туган җире – Актанышы белән дә арасын өзми. Берәр чара оештырсалар да, Казанда якташлар бәйрәмен үткәрсәләр дә, аларның берсе дә Фәйрүзәсез үтми. Язучылар берлегендә дә ул – үз кеше. Яшь язучыларны әгъзалыкка кабул итү буенча комиссиядә эшли, китапларга рецензияләр яза, тәрҗемә белән дә шөгыльләнә. «Бик җаваплы кеше иде. Әйттеме – эшли», – дип әйтәләр аның хакында.

Бүген аның хезмәттәшләре, якыннары истәлекләр барлый. «Иң якын, иң саф күңелле, иң якын кешем иде ул…» «Фәйрүзә кебек ак күңелле кеше дөньяда тагын бар микән? Белмим…» «Ул керүгә, кояш чыккан сыман дөньялар яктырып китә иде…» «Шулкадәр нурлы кеше иде ул. Беркайчан беркемне яманламады. Дәүләтне дә, хөкүмәтне дә сүкмәде. Тормыштан рәхәтлек таба белде». Хәер, үтә гади, йомшак кеше дә түгел иде Фәйрүзә апа. Журналист Эльмира Закирова аның турында: «Фәйрүзә апа… җегет иде! Һәр нәрсәгә үз карашы, позициясе бар, әйтсә, сүзен өздереп әйтә, ярымтоннарга урын калдырмый. Тәвәккәл, кыю, яраклашуларга, провокацияләргә бирелмәс һәм бирешмәс. Шул ук вакытта бөтенләй капма-каршы фикерле кешеләр белән аралаша, араларында бизмән ролен үти иде ул».

Бүген, сүз дә юк, бу югалту Камил абый, балалары Илдар белән Диләрә өчен бигрәк тә авыр. «Табиблар, йөрәге таза, диделәр. Шуңа күрә, хәле бик авыр булса да, терелүенә өмет бар иде. Ясалма комадан чыга алмады», – ди Камил абый. Аннан истәлекләргә бирелде. «Фәйрүзә чын мәгънәсендә иҗади шәхес булды. Бу дөньяның ваклыклары белән матавыкланып тормады. Бер чамага туры килеп, ашарына ипи, эчәренә чәй булса, шуңа шөкер итеп яшәде. Күп акчаны кирәксенмәде, булганын бәрәкәтле итеп тота белде. Дәрәҗәгә, данга омтылмады. Ак күңелле кеше иде ул. Микроскоп аша эзләсәм дә, бер генә гаебен дә таба алмыйм. Шулай булса да, нишләптер, бик авыр китте. Шуңа бигрәк тә күңел әрни. Утыз көн үлем белән тартышты. Уйланып та яткан, күрәсең. Соңгы тапкыр очрашканда: «Башкачарак та була иде яшәргә», – дип уфтанып куйгандай булды. Иҗат кешесе, дин юлындагы кеше буларак, ничектер, үзенчәрәк яшәргә ияләшкән иде ул. Күпме чакырсам да, минем янга авылга килеп яшисе итмәде. Шәһәр тормышын үз итте. Мин дә йортны ташлап китә алмадым. Бу юлы: «Балалар, оныклар янәшәсендә яшисем килә», – диде. Алар белән ял көннәрендә генә очраша ала иде шул. Бу фикерне кызыма да әйткән. Үзебез дә шулай уйлый идек. Диләрә, яңа йорт салганда, әнисенә дип аерым бүлмә дә тәгаенләде. Әле Фәйрүзә авырып киткәнче, Коръән ашы уздырып алды. Әнисе бик куанып йөрде шунда, бүлмәсен дә бик ошатты. Яңа ел алдыннан бергәләп өй туе үткәрмәкче идек. Нишлисең, язмаган булган икән».

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе коллективы хезмәттәшебез Камил Сәгъдәтшинның, улы Илдар, кызы Диләрәнең, туганнарының, якыннарының авыр кайгысын уртаклаша. Фәйрүзә апаның урыны җәннәттә булсын. Калганнарга Ходай сабырлык бирсен.

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

«Татмедиа» Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы коллективы, журналист, шагыйрә һәм язучы, Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре, Абдулла Алиш исемендәге әдәби премия лауреаты
Фәйрүзә Әсгат кызы МӨСЛИМОВАның
вафат булуы сәбәпле, туганнары һәм якыннарының авыр кайгысын уртаклаша.

Спас районы якташлары, Иске Рәҗәп авыл җирлеге Советы һәм авыл халкы, шагыйрә
Фәйрүзә МӨСЛИМОВАның
вафат булуы сәбәпле, авылдашыбыз журналист, шагыйрь, Болгар якташлык җәмгыяте рәисе, «Ватаным Татарстан» газетасының махсус хәбәрчесе Камил Сәгъдәтшинның гаиләсенең һәм туганнарының авыр кайгысын уртаклаша.

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы, Бөек Ватан сугышы ветераны, озак еллар буе агросәнәгать комплексы өлкәсендә эшләгән
Мөхәммәт Зариф улы ИСХАКОВның
вафат булуы сәбәпле, мәрхүмнең гаиләсе һәм якыннарының авыр кайгысын уртаклаша.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОННАРЫ

«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы
тарафыннан 2021 елның 25 октябрендә кабул ителде

1 статья
«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» 2003 елның 28 ноябрендәге 49-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 1 өлешенә (2010 елның 5 июлендәге 51-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 11; 2010, № 7 (II өлеш); 2011, № 5, № 8 (I өлеш); 2012, № 2, № 6 (I өлеш); 2013, № 3, № 6 (II өлеш), № 10, № 12 (I өлеш); 2014, № 10 (I өлеш); 2015, № 6 (I өлеш), № 8 – 9; 2016, № 1 – 2, № 6 (III өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 44 (I өлеш); 2017, № 1 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 50 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 54 (I өлеш); 2019, № 49 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 36 (I өлеш), № 49 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
1) 1 пунктта «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законы нигезендә» сүзләрен «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» 1998 елның 25 ноябрендәге 1872 номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законы) нигезендә» сүзләренә алмаштырырга;
2) түбәндәге эчтәлекле 19 пункт өстәргә:
«19) «Электр энергиясен һәм егәрлеген күпләп сату базары кагыйдәләрен раслау турында һәм электр энергиясен һәм егәрлеген күпләп сату базарының эшләвен оештыру мәсьәләләре буенча Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 27 декабрендәге 1172 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә үткәрелгән конкурс нәтиҗәләре буенча сайлап алынган җитештерү һәм куллану калдыкларыннан файдалану нигезендә эшли торган генерация объектларын төзү (реконструкцияләү, модернизацияләү) буенча инвестиция проектларын гамәлгә ашыручы оешмалар – «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законы нигезендә төзелгән инвестиция проектын гамәлгә ашыру турындагы шартнамәгә ярашлы рәвештә эшчәнлекне гамәлгә ашыру максатларында яңа төзелгән яисә сатып алынган, оешма балансында исәптә булган мөлкәткә карата.
Салым ташламасы, объект файдалануга тапшырылган айдан соң килүче айның 1 числосыннан башлап, инвестиция проектын гамәлгә ашыру турында шартнамә гамәлдә булган, әмма 15 елдан да артмаган срокка бирелә.
Инвестиция проектын гамәлгә ашыру турындагы шартнамәнең гамәлдә булу чорында оешма әлеге пунктта каралган салым ташламасын түбәндәге шартларны үтәгәндә кулланырга хокуклы:
бизнес-планда каралган шартлар үтәү;
хисап елында Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджетына оешмалар табышына салымның, физик затлар керемнәрә салымның, оешмалар мөлкәтенә салымның, транспорт салымының, җир салымының кушма суммалары һәм тиешле пенялар һәм штрафлар суммалары (салымнар буенча недоимка, пенялар һәм штрафлар буенча бурычлар суммаларының һәм оешмалар табышына салым һәм оешмалар мөлкәтенә салым өлешендә артык түләнгән яисә артык түләтелгән салымнар (пенялар, штрафлар) суммаларының үзгәрешләре йогынтысын исәпкә алмыйча), хисап елына кадәрге өч ел өчен булып (йә, оешма төзелгән вакытны исәпкә алып һәм әлеге пунктның җиденче абзацын исәпкә алып, хисап елына кадәрге башка чор өчен, ләкин ике елдан күбрәк түгел), тиешле тармак буенча тулаем Россия Федерациясендә Россия Федерациясе субъектларының берләштерелгән бюджетларына салымнардан кергән акчалар суммасы үзгәрү күрсәткеченә, ул салымнар һәм җыемнар өлкәсендә контроль һәм күзәтчелек буенча вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы тарафыннан раслана торган форма буенча тапшырыла торган тиешле ел өчен икътисадый эшчәнлекнең төп төрләре буенча Россия Федерациясе бюджет системасына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәре исәпләп бирелү һәм түләнү турындагы хисап белешмәләренә нигезләнеп билгеләнә, һәр ел йомгаклары буенча индексацияләнгән тиешле салымнарның (пеняларның, штрафларның) (салым ташламаларыннан файдалану өлешендә чагыштырма шартларда) оешма тарафыннан чынбарлыкта түләнгән суммаларының уртача арифметик күрсәткеченнән ким булмаган күләмдә түләнү;
Татарстан Республикасы финанс органына оешмага исәпләп бирелгән һәм аның тарафыннан түләнгән салымнар суммалары, салымнар буенча недоимка, пенялар һәм штрафлар буенча бурычлар суммалары һәм артык түләнгән яисә артык түләтелгән салымнар (пенялар, штрафлар) суммалары, бирелгән салым ташламаларының ташламалар киселешендәге суммалары турында белешмәләрне салым органы тарафыннан бирүгә ризалык бирелгән булу.
Яңа төзелгән оешма салым ташламасын салым буенча беренче салым чоры йомгаклары буенча, шушы пунктның дүртенче абзацында билгеләнгән шартны үтәмичә, әлеге пункт нигезендә кулланырга хокуклы.
Салым ташламасын әлеге пункт нигезендә куллануның шушы пунктның бишенче абзацында билгеләнгән шартының оешма тарафыннан үтәлүен бәяләү тәртибе һәм методикасы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана. Мондый тәртиптә тиешле тармак буенча тулаем Россия Федерациясендә Россия Федерациясе субъектларының берләштерелгән бюджетларына салымнардан кергән акчалар суммасы үзгәрү күрсәткечен исәпләп чыгару методикасы булырга тиеш.».

2 статья
Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль. 2021 ел, 03 ноябрь
№ 83-ТРЗ

«Татарстан Республикасында халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Законының 2 һәм 2^1 статьяларына һәм «Инвалидлар һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнар өчен эш урыннары квоталау һәм резервлау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы
тарафыннан 2021 елның 25 октябрендә кабул ителде

1 статья
«Татарстан Республикасында халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру турында» 2006 елның 19 июнендәге 39-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 6 (I өлеш); 2007, № 4; 2011, № 8 (I өлеш); 2012, № 12 (I өлеш); 2014, № 6 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2015, № 5, № 10 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 27 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 51 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
1) 2 статьяның 2 һәм 4 пунктларын үз көчләрен югалткан дип танырга;
2) 2^1 статьяда:
а) 3 өлештә:
1 пунктта:
икенче – дүртенче абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«билгеләнгән тәртиптә эшсезләр дип танылган гражданнарга һәм билгеләнгән тәртиптә эшсезләр дип танылган һәм халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнары юлламасы буенча һөнәри уку узган яисә өстәмә һөнәри белем алган гражданнарга индивидуаль эшкуар буларак дәүләт теркәвенә куелганда, төзелә торган юридик зат дәүләт теркәвенә куелганда, крестьян (фермер) хуҗалыгы дәүләт теркәвенә куелганда, физик зат һөнәри керемгә салымның салым түләүчесе буларак исәпкә куелганда бер мәртәбә финанс ярдәме күрсәтү тәртибен, шартларын һәм күләмен;
өч яшькә кадәрге бала карау ялында булу чорында хатын-кызларны, Россия Федерациясе законнары нигезендә картлык буенча иминият пенсиясе билгеләнгән һәм хезмәт эшчәнлеген торгызырга омтылган эш белән тәэмин ителмәгән гражданнарны халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнары тарафыннан һөнәри уку узуга яисә өстәмә һөнәри белем алуга юллау тәртибен һәм шартларын;
һөнәри уку узу яисә өстәмә һөнәри белем алу өчен халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнары тарафыннан башка җиргә юлланган эшсез гражданнарга һәм өч яшькә кадәрге бала карау ялында булу чорында хатын-кызларга, шулай ук Россия Федерациясе законнары нигезендә картлык буенча иминият пенсиясе билгеләнгән һәм хезмәт эшчәнлеген торгызырга омтылган эш белән тәэмин ителмәгән гражданнарга финанс ярдәме күрсәтү тәртибен, шулай ук күрсәтелгән финанс ярдәменең күләмнәрен;»;
түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:
«буш эш урыннарын, вакантлы вазыйфаларны биләү максатларында, шул исәптән инвалидларны эшкә алу өчен билгеләнгән квота кысаларында, эш белән тәэмин итү хезмәте органнарының эш бирүчеләр (эш урыннарын, инвалидларны эшкә урнаштыру өчен махсус эш урыннарын да кертеп, оештыру, буш эш урыннарын, вакантлы вазыйфаларны биләү өчен инвалидларны сайлап алу мәсьәләләре буенча) һәм инвалидлар арасыннан булган гражданнар өчен һөнәри белем бирүнең уку-укыту программалары буенча һәм (яисә) өстәмә һөнәри программалар буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмалар белән үзара хезмәттәшлек итү тәртибен һәм шартларын;»;
2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«2) эштән җибәрү куркынычы янаган гражданнарны, шулай ук социаль яклауга аеруча мохтаҗ һәм эш эзләүдә кыенлыклар кичерүче гражданнарны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү программаларын да кертеп, халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү, шул исәптән инвалидларны эшкә урнаштыруга һәм эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәткәндә булышып торуны оештыру чараларын күздә тота торган региональ программаларны, Социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча республика өчьяклы комиссиясе фикерен исәпкә алып, эшләү һәм мондый программаларны гамәлгә ашыру;»;
3 пунктта «өстәмә чаралар» сүзләреннән соң «, шул исәптән инвалидларны эшкә урнаштыруга һәм эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү чараларын кертеп,» сүзләрен өстәргә;
б) 4 өлештә:
4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«4) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан расланган нигезләмәгә таянып, билгеләнгән квота чикләрендә инвалидларны эшкә алуга региональ дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру;»;
түбәндәге эчтәлекле 4^1 пункт өстәргә:
«4^1) халыкны эш белән тәэмин итү хезмәтенең дәүләт учреждениеләренә карата инвалидларны эшсезләр буларак теркәүгә һәм халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт гарантияләрен тәэмин итүгә контрольне гамәлгә ашыру, моңа «Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» 1991 елның 19 апрелендәге 1032-1 номерлы Россия Федерациясе Законының 7 статьясындагы 3 пунктының 11 пунктчасында каралган вәкаләтләр керми;»;
6 пунктта:
икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«яраклы эш эзләүдә гражданнарга ярдәм итү;»;
җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«башка җирдә укытуны да кертеп, эшсез гражданнарны һөнәри укытуны һәм аларга өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру;»;
сигезенче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;
тугызынчы абзацта «урта һөнәри белеме булган һәм беренче мәртәбә эш эзләүче 18 яшьтән 20 яшькә кадәрге» сүзләрен «урта һөнәри белеме яисә югары белеме булган һәм белеме турында һәм квалификация турында үзенә документ бирелгән датадан башлап бер ел дәвамында эш эзләүче 18 яшьтән 25 яшькә кадәрге гражданнар» сүзләренә алмаштырырга;
унберенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«билгеләнгән тәртиптә эшсезләр дип танылган гражданнарга, билгеләнгән тәртиптә эшсезләр дип танылган һәм халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнары юлламасы буенча һөнәри уку узган яисә өстәмә һөнәри белем алган гражданнарга индивидуаль эшкуар буларак дәүләт теркәвенә куелганда, төзелә торган юридик зат дәүләт теркәвенә куелганда, крестьян (фермер) хуҗалыгы дәүләт теркәвенә куелганда, физик зат һөнәри керемгә салымның салым түләүчесе буларак исәпкә куелганда бер мәртәбә финанс ярдәме күрсәтүне кертеп, эшсез гражданнарның эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыра башлавына булышу;»;
түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:
«кирәкле хезмәткәрләрне сайлап алуда эш бирүчеләргә булышу;»;
7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«7) эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәткәндә, хезмәт базарында барлыкка килә торган вәзгыятьне исәпкә алып, яраклы эш эзләү максатларында теркәлгән гражданнарга һәм эш бирүчеләргә нәтиҗәле ярдәм итү максатларында, әлеге гражданнарны профильләштерү (күрсәтелгән гражданнарны аларның элеккеге һөнәри эшчәнлеге өлкәсенә, җенесенә, яшенә һәм башка социаль-демографик характеристикаларына, шулай ук хезмәт базарындагы статусына, эшкә урнашу потенциалына һәм эшкә урнашуга мотивациясенә бәйле рәвештә төркемнәргә бүлү), шулай ук эш бирүчеләрне профильләштерү (эш бирүчеләрне оештыру-хокукый рәвешләренә, икътисадый эшчәнлек төренә, финанс-икътисадый торышына, хезмәт шартларына, хезмәт хакы дәрәҗәсенә һәм башка характеристикаларга бәйле рәвештә төркемнәргә бүлү) буенча махсус чаралар оештыру һәм үткәрү;»;
түбәндәге эчтәлекле 10^9 пункт өстәргә:
«10^9) түләүле җәмәгать эшләре башкаруны оештыру;»;
в) 6 өлешне үз көчен югалткан дип танырга;
г) түбәндәге эчтәлекле 7 – 9 өлешләр өстәргә:
«7. Билгеләнгән квота чикләрендә инвалидларны эшкә алуга региональ дәүләт контроленең (күзәтчелегенең) предметы эш урыннарын квоталау өлкәсендә Россия Федерациясе норматив хокукый актларында һәм Россия Федерациясе субъектлары норматив хокукый актларында билгеләнгән мәҗбүри таләпләрнең эш бирүчеләр тарафыннан үтәлешеннән гыйбарәт.
8. Билгеләнгән квота чикләрендә инвалидларны эшкә алуга региональ дәүләт контролен (күзәтчелеген) оештыру һәм гамәлгә ашыру «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон белән җайга салына.
9. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә вәкаләтләрне гамәлгә ашырганда, башка оешмалар белән үзара хезмәттәшлек итүне оештырырга хокуклы.».

2 статья
«Инвалидлар һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнар өчен эш урыннары квоталау һәм резервлау турында» 2006 елның 24 июлендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 7 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 7; 2014, № 6 (II өлеш), № 12 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2019, № 2 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
1) 2 статьяның 3 пунктындагы тугызынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«урта һөнәри белеме яисә югары белеме булган һәм белеме турында һәм квалификация турында үзенә документ бирелгән датадан башлап бер ел дәвамында эш эзләүче 18 яшьтән 25 яшькә кадәрге гражданнар;»;
2) 3 статьяда:
а) түбәндәге эчтәлекле 1^1 һәм 1^2 өлешләр өстәргә:
«1^1. Инвалидларны эшкә алу өчен квота исәпләп чыгару максатларында хезмәткәрләрнең саны, эш бирүченең Россия Федерациясенең башка субъектларында урнашкан филиаллары һәм вәкиллекләре хезмәткәрләрен исәпкә алмыйча, хезмәткәрләрнең исемлектәге уртача саныннан чыгып билгеләнә.
1^2. Россия Федерациясенең башка субъектларында урнашкан эш бирүченең Татарстан Республикасы территориясендәге филиалларына һәм вәкиллекләренә инвалидларны эшкә алу өчен квота, эш бирүченең мондый филиаллары һәм вәкиллекләре хезмәткәрләренең исемлектәге уртача саныннан чыгып, әлеге Закон нигезендә билгеләнә.»;
б) 5 өлештә «хезмәт шартлары буенча эш урыннарына аттестация үткәрү яисә» сүзләрен төшереп калдырырга;
в) түбәндәге эчтәлекле 11 һәм 12 өлешләр өстәргә:
«11. Эш бирүче билгеләнгән квота нигезендә инвалидларны эшкә урнаштыру бурычын үтәү кысаларында инвалидлар белән хезмәт мөнәсәбәтләре билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән очракта, инвалидларны эшкә алу өчен квота эш бирүче тарафыннан башкарылган дип санала.
12. Эш бирүченең теләсә нинди эш урынына инвалид белән хезмәт мөнәсәбәтләрен билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерүе Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән очракларда һәм тәртиптә инвалидларны эшкә алу өчен квотаның үтәлүе дип санала.»;
3) 6 статьяның 2 өлешендәге 3 пунктында «реабилитацияләүнең» сүзеннән соң «яисә абилитацияләүнең» сүзләрен өстәргә.

3 статья
1. Әлеге Закон, бу статьяда үз көченә керүнең бүтән сроклары билгеләнгән нигезләмәләреннән тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 2 пунктының «б» пунктчасындагы унҗиденче һәм унсигезенче абзацлар 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.
3. Әлеге Законның 2 статьясындагы 2 пункты 2022 елның 1 мартыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль. 2021 ел, 03 ноябрь
№ 84-ТРЗ

Гражданнарның гаражларга һәм алар урнашкан җир кишәрлекләренә хокуклар алуына бәйле аерым мәсьәләләрне җайга салу турында һәм Татарстан Республикасы Җир кодексының 3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы
тарафыннан 2021 елның 25 октябрендә кабул ителде

1 статья. **Әлеге Законның җайга салу предметы**
Әлеге Закон «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 5 апрелендәге 79-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә (алга таба – Федераль закон) гражданнарның үзләре файдалана торган, Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрында хокуклар теркәлмәгән гаражларга (алга таба – гаражлар) һәм алар урнашкан җир кишәрлекләренә хокуклар алуына бәйле аерым мәсьәләләрне җайга сала.

2 статья. **Гражданнарның гаражларга һәм алар урнашкан җир кишәрлекләренә хокуклар алуына бәйле мәсьәләләрне хәл итү өлкәсендә Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнарының һәм дәүләт хакимияте органнарының хокуклары**
1. Федераль закон нигезендә җирлекләрнең, шәһәр округларының җирле үзидарә органнары (алга таба – җирле үзидарә органнары) тиешле муниципаль берәмлекләр чикләрендә урнашкан гаражлардан файдаланучы затларны (алга таба – гаражлардан файдаланучы затлар) ачыклауга юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыруга һәм гражданнарга гаражларга һәм алар урнашкан җир кишәрлекләренә хокуклар алуда ярдәм күрсәтергә хокуклы.
2. Гаражлардан файдаланучы затларны ачыклауга һәм гражданнарга гаражларга һәм алар урнашкан җир кишәрлекләренә хокуклар алуда ярдәм күрсәтүгә юнәлдерелгән чаралар шулай ук муниципаль районнарның җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә ашырылырга мөмкин.
3. Җирле үзидарә органнары, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең җир мөнәсәбәтләре өлкәсендә вәкаләтле органы әлеге статьяда күрсәтелгән объектларга карата кадастр эшләрен яисә комплекслы кадастр эшләрен башкаруны тәэмин итәргә хокуклы.

3 статья. **Гаражлардан файдаланучы затларны ачыклауга юнәлдерелгән чаралар**
1. Гаражлардан файдаланучы затларны ачыклауга юнәлдерелгән чараларга түбәндәгеләр керә:
1) гаражлардан файдаланучы затлар турындагы белешмәләрне, шул исәптән архивларда һәм (яисә) җирле үзидарә органнары карамагында булган документлардагы белешмәләрне, шулай ук гаражларның, гараж һәм гараж-төзелеш кооперативларының урнашуы турындагы белешмәләрне, генераль планнарда һәм җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрендә булганнарын да кертеп, җыю һәм анализлау;
2) гаражлардан файдаланучы затлар турында белешмәләр алу максатларында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына, оешмаларга, шул исәптән «Күчемсез мөлкәткә хокукларны һәм алар белән алыш-бирешне дәүләт теркәве турында» 1997 елның 122-ФЗ номерлы Федераль закон үз көченә кергәнче күчемсез мөлкәт объектларына хокукларны исәпкә алуны һәм теркәүне гамәлгә ашырган оешмаларга, нотариусларга гарызнамәләр җибәрү;
3) гражданнарга гаражларга һәм алар урнашкан җир кишәрлекләренә хокуклар алуның шартлары һәм тәртибе, шулай ук барлык кызыксынучы затлар тарафыннан гаражлардан файдаланучы затлар турында белешмәләрне җирле үзидарә органнарына җиткерү тәртибе һәм алымнары хакында мәгълүмат бирү.
2. Җирле үзидарә органнары гаражлардан файдаланучы затларны ачыклауга юнәлдерелгән башка чараларны гамәлгә ашырырга хокуклы.

4 статья. **Гаражлардан файдаланучы затларны ачыклауга юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыру тәртибе**
1. Гражданнарга әлеге Законның 3 статьясындагы 1 өлешенең 3 пунктында каралган мәгълүмат җиткерү тиешле мәгълүматны муниципаль хокукый актларны рәсми бастырып чыгару өчен билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгару, аны вәкаләтле органның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтына, территориясендә гаражлар урнашкан торак пункт чикләрендә йә торак пункт чикләреннән читтә урнашкан башка территориядә (гаражлардан файдаланучы затларны торак пункт чикләреннән читтә ачыклау буенча эшләр башкарылган очракта) урнаштыру юлы белән, шулай ук аның максималь таралуын тәэмин итә торган башка алымнар белән гамәлгә ашырыла.
2. Җирле үзидарә органнарына гаражлардан файдаланучы затлар турындагы белешмәләр, шул исәптән гаражларга гражданнарның хокукларын раслый торган документлар, күрсәтелгән затлар белән элемтәгә керү өчен почта адресы һәм (яисә) электрон почта адресы турындагы белешмәләр гаражлардан файдаланучы затлар (аларның вәкаләтле вәкилләре) йә гаражлардан файдаланучы затларны ачыклау хокукларына һәм законлы мәнфәгатьләренә кагылырга мөмкин башка затлар тарафыннан тапшырылырга мөмкин.
3. Гаражлардан файдаланучы затлар ачыкланган очракта, җирле үзидарә органы күрсәтелгән затлар ачыкланган көннән алып 10 эш көне эчендә, гаражларга һәм алар урнашкан җир кишәрлекләренә хокук алуда ярдәм күрсәтү өчен җирле үзидарә органына мөрәҗәгать итәргә тәкъдим итеп, аларга почта аша яисә мөмкин булган башка алымнар белән мәгълүмат җибәрә.

5 статья. **Татарстан Республикасы Җир кодексының 3 статьясына үзгәрешләр кертү турында**
Татарстан Республикасы Җир кодексының 3 статьясына (2005 елның 18 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 8 (II өлеш); 2005, № 1 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 1 (I өлеш), № 4; 2008, № 5 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (III өлеш); 2010, № 11; 2011, № 11 (I өлеш); 2012, № 3, № 5 (I өлеш); 2013, № 1; 2014, № 3, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш); 2017, № 41 (I өлеш), № 52 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 22 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 60 (I өлеш); 2020, № 77 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 20 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 57 (I өлеш) №77 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
1) түбәндәге эчтәлекле 6^3 пунктчасын өстәргә:
«6^3) җирле үзидарә органнары тарафыннан инвалидларның яшәү урынына якын җирдә капиталь корылма булмаган гаражлар һәм инвалидларның техник һәм башка хәрәкәтләнү чараларын кую урынын урнаштыру схемаларын раслау тәртибен билгеләү;»;
2) түбәндәге эчтәлекле 6^4 пунктчасын өстәргә:
«6^4) гражданнар тарафыннан капиталь корылма булмаган гаражлар кую өчен Татарстан Республикасы милкендә булган җир кишәрлекләреннән, дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдән яисә җир кишәрлекләреннән файдаланган өчен түләүне билгеләү тәртибен урнаштыру;».

6 статья. **Әлеге Законның үз көченә керүе**
Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль. 2021 ел, 03 ноябрь
№ 85-ТРЗ

Һәркем уяу булсын

ТАТАР ЯЗУЧЫЛАРЫНЫҢ ТАТАР ХАЛКЫНА МӨРӘҖӘГАТЕ

Җанисәп – 2021

Бөтендөнья Язучылар оешмасы ПЕН-клубның Татар әдипләре бүлеге Бөтенроссия халык исәбен алу уңаеннан мөрәҗәгать белән чыкты. Әлеге мөрәҗәгатьне сезнең игътибарга да тәкъдим итәбез.

Тарихи яшәеш дәвамында халкыбыз төрле сынаулар кичергән. Алар арасында кайтарып булмаслык югалтуларга китергәне дә, тарих чынбарлыгында килеп туган каршылыкларга мөнәсәбәтлеләре дә, җәмгыять тормышының ясалма киртәләренә бәйлеләре дә байтак. Шөкер, газиз милләтебез мондый авырлыклардан этник бөтенлеген саклап, үзенә файдалы сабакларны үзләштергән хәлдә чыга белде.

Һәммәбезгә билгеле булганча, шушы көннәрдә Россия Федерациясендә халык санын алу үткәрелә. Безнең өчен монысы да – җитди сынау. Әледән-әле оештырылып килгән илкүләм җанисәптә аерым гаделсезлекләргә, нәтиҗәләрне бозып күрсәтүгә юл куелуын да күрдек. Кызганыч ки, татар халкы үзенең төгәл санын шушы көнгә кадәр белә алмый. Теләсә нинди кавемнең якты киләчәккә омтылган яшәеше мәгълүм дәрәҗәдә ошбу стратегик исәпкә дә бәйле. Күпне кичергән милләт вәкилләре табигый хокукларын яклауга, үзләренең гомуми исәбен дөресләп тәгаенләүгә һичшиксез лаек.

Без – татарлар. Этносәяси бергәлек буларак, урта гасырларда ук үзенең барлыгын белдергән, тирән тамырлы дәүләтчелек традицияләрен барлыкка китергән, кайбер башка кавемнәрне дә ил-көн белән идарә итәргә өйрәткән, сан-исәп буенча ил күләмендә икенче урынны биләгән халык… Безне зур милләт статусында гәүдәләндергән мәгълүмати исемлеккә әле тагын өстәргә мөмкин. БМОның Тел комиссиясе татар телен дөньяның теләсә кайсы тарафында аңлашып була торган 14 телнең берсе дип игълан итте. Рухи тормышыбызның асыл нигезен билгеләгән әдәбият-сәнгать казанышларыбызда ничәмә-ничә буынның акыл һәм талант көче тупланган.

Олы максатларга юнәлдерелгән тырыш хезмәтнең күркәм нәтиҗәсен чагылдырып, татар факторы планетаның барча кыйблаларында үзен таныта бара.

Мондый иҗтиһатлы халык бәләкәй була алмый. Бүгенге глобаль дөньяда гомуми саны төрле астыртын алымнар белән даими киметелеп күрсәтелгән кавемнең сәяси, икътисади һәм социаль мәсьәләләрне милләт файдасына чишүдә дә потенциаль мөмкинлекләре үзеннән-үзе азаячак. Безгә насыйп кылынган хәләл өлешне читләр тартып алырга тиеш түгел. Мәдәниятне, туган телне, гореф-гадәтләрне, милли үзенчәлекләрне ирешелгән биеклектән төшмичә, элекке зурлыгын җуймаган какшамас бергәлектә генә саклап калырга мөмкин. Боларны балаларыбызга да бик нечкәләп аңлатыйк!

Без башка милләт вәкилен татар итеп яздырырга, үзебезне ясалма рәвештә ишәйтергә беркайчан да ымсынмадык. Шул ук вакытта татарлар да, ихтыярлы-ихтыярсыз, бүтән кавемне күбәйтергә тиеш түгел. Бу чын-чынлап хәрәмләшүгә керә. Газиз өммәт варисын карында мөкатдәс йөктәй күтәреп йөртмичә генә, тулгаклау газапларын кичермичә, мөстәкыйль халык баласының милләтен башбаштакларча алыштырып кую гөнаһка тиңдер.

Сөекле милләттәшләр! Бөтенроссия халык исәбен алу вакытында һәркемнең аеруча уяу булуы сорала. Татарстанның яңа дәүләтчелеге шартларында горурлык тойгысының ныгуы безнең бердәм милләт рәвешендә яшәү омтылышын көчәйтсен. Барлык интеллектуаль һәм оештыру сәләтебезне милли асылыбызны саклап калуга, аерым төркемнәргә бүлгәләнмичә, бүгенге тормышыбызга ышанычлы нигез әзерләгән элгәрләребезгә тугрылык күрсәтүгә юнәлтик. Чираттагы җанисәп нәтиҗәләре кавемебезнең куәтен арттырсын. Зурлыгыбызны раслаган хәлдә генә татар халкының төрле яклап үсүен тәэмин итәрбез, бүгенге четерекле дөньяда киләчәк буыннар да рәхмәт әйтерлек күркәм казанышларга ирешә алырбыз.

Дөнья халкы безне элек-электән татар буларак белә. Киләчәктә дә үз милләтебезне саклап, татар исеме белән горурланып яшик.

АГАҢ БУЛСА ГАЛИМ...

КАМАЛ ТЕАТРЫ СӘХНӘСЕНДӘ – ТАТАР-БАШКОРТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ

Премьера

980 чакрым. Бер анадан туган ике бала арасында сузылып яткан юл бу. Ике дистә ел буена әллә ничә кат саналган чакрымнар. Хәзерге заман өчен күп тә түгел кебек инде. Ләкин ул чакрымнардан уйламыйча әйтелгән сүзләр кайтавазы ишетелсә? Бу юлны узуга нәселен сызып ташлаган агайга карата үпкә, нәфрәт комачауласа?

kamalteatr.ru

Камал театры яңа сезонының беренче премьерасын тәкъдим итте. «Сәфәр» дигән пьесаны «Юлчы» тапшыруын алып баручы Альберт Шакиров язган. Режиссеры – Рамил Гәрәев. Сәнгать җитәкчесе – театрның баш режиссеры Фәрит Бикчәнтәев.

Авыл. Вакыйгалар Татарстандагы Черкиле авылында башлана һәм Башкортстандагы Актау авылында тәмамлана. Географик атамалар мөһим түгел, гадәти авыллар инде. «Авыл бу, авыл. Ярминкәгә барып, сөтеңне сат, сайлауга барып, тавышыңны бир. Бирсәләр, ал, сорамасалар, эндәшмә». «Салган килеш беркайчан да намазга басмый торган» мулла да, тол калган әче телле күрше хатыны да, үзе биргән вәгъдәләрдән үзенең башы әйләнгән авыл советы башлыгы да, иманын кәгазьгә алыштырган «полиционер» да бер талашып, бер дуслашып, вакыт-вакыт урысча белән татарчаны катнаштырып яши бирә. Сабый күңелле, әмма тормышта күпне күргән Сәфәргали карт һәм аның газиз баласын югалтканнан соң акылы җиңеләеп калган кызы да – шулар арасында. «Һәр авылда була торган кешеләрдер инде ул. Кайсыларының прототибы – конкрет бер кеше, кайсылары – җыелма образ», – диде бу хакта пьесаның авторы Альберт Шакиров.

«Сәфәр» – моңсу комедия. Аның моңсу комедия дип әйтерлеге менә шушы геройларның диалогларында чагыла да кебек инде. Башка мәсьәләләрдән бигрәк әлеге дә баягы авыл темасы пьесага юнәлеш бирә. Тамашачыга да шушы ягы белән якын булыр төсле ул. Чөнки ничек бар, шулай тасвирланган.

Туганлык. Аны нәрсә боза ала? Таң атканчы күккә карап һәм серләшеп утырган ага-эне арасына каяндыр килеп кергән милли мәсьәләме? Татар өчен тамак ертып йөргән туганыңның кисәк кенә башкортка әйләнүеме? Икең дә нык нигезле гаиләдә үс тә, аннан икең ике якта ят, имеш. 20 ел буена бер сүз дә дәшмичә. «Башкорт ни дә, татар ни – барыбыз да адәм балалары». Спектакльдә бу сүзләр дә яңгырый, әмма аларны юлда очраган бер эпизодик герой гына әйтә. Төп герой – Сәфәргали карт исә бөтенләй башка сүзләр сөйли: «Башкорт Башкортстанда яшәргә тиеш», «Нәселне сызып ташлады», «Гүргә кергән әткәй башкортка әйләнде дә куйды». Әле халык санын исәпкә алу төгәлләнеп бетмәгән көннәрдә, кемнәрдер эләктереп алып ут кабызырдай, «хайп»ка нигезләнгән урыннарны дәүләт театры статусын йөртүче камаллылар ни өчен күрмәде яисә күрергә теләмәде икән?

– Спектакль Марсель Сәлимҗановның туган көненә туры китереп әзерләнде. Күренекле режиссерның туган көнен премьера белән каршылау – Камал театрының матур бер традициясе. Аны беркайчан да бозмадылар. Премьерага билгеләнгән көннәр халык санын алу көннәре белән бер вакытта туры килде. Очраклы рәвештә. Бу – көн кадагында торган темага алынып, махсус шушы көннәргә туры китереп эшләнгән әйбер түгел. Җанисәп уздыруның көннәре үзгәреп торганын исәпкә алсаң, бигрәк тә. Гомумән, татар-башкорт мөнәсәбәтләре – соңгы берничә елда гел игътибар үзәгендәге тема. Әлеге тарткалашуларның соңгы елларда гына түгел, бик күптәннән баруы билгеле. Бүген – аның кискенләшкән вакыты гына. Чоры шундый булгач, аңа күпмедер дәрәҗәдә спектакльдә дә рефлексия ясалды, – дип аңлатты безгә Альберт Шакиров.

Тик ни дәрәҗәдә кирәк соң бу «актуаль тема»ның сәхнәгә күтәрелүе? Күтәрелә икән, ни өчен мондый эшләнеп бетмәгән, «яшел» дәрәҗәдә? Бу бүген инде модага кергән «арзанлы хайп»ка иярү генә түгелме? Алай дисәң, бүгенге театр тамашачысы мондый темаларга ни дәрәҗәдә мөкиббән? Кыскасы, сораулар күп калды. Бер нәрсә бәхәссез: спектакльне актерлар уены күтәреп чыга. Ә алар шәп уйный!

Сүз көче. Аның белән бәйле гыйбарәләр күп яңгырады спектакльдә. Монда туган белән туган арасын да сүз бозган, чөнки «иң авыр сүзне иң якын кешең әйтә». Сәфәргали дә ахырдан, буталдык, дими, ялгышып, артыгын әйтеп ташладык, ди. Ике туганны 20 елга аерып куюда да сүз гаепле. Ләкин Сәфәргали абыйсы Муллагали белән күрешкәч, тынлык урнаша һәм спектакль шул урында өзелә дә. Ни өчен өзелә, дим, чөнки Муллагалидән дә һич югы аклану сүзләре ишетәсе килгән иде. Без аның галим булганын, архивларда актарынып, нәселләренең башкортка барып тоташуын ачыклаганын һәм энесенә үзләренең башкорт булуын исбат итәргә тырышуын гына беләбез. «Ни өчен ике туган күрешкәч тә сөйләшмәде? Бу сорауны миңа инде берничә кеше бирде. Сәфәргали, абыйсы янына барганда, үзе дә: «20 елдан соң нинди генә сүзләр табарбыз», – дип әйтә бит. 20 ел сөйләшми торганнан соң сүз башлау, дөрестән дә, авырдыр ул. Муллагалигә бөтенләй сүз бирмәдек. Ә без аңа сүз биреп, нәрсә ишетергә телибез икән? Ул ике генә сүз әйтә ала: «Мин ялгыштым, мин – сатлыкҗан, энем, гафу ит» яисә «Юк, мин дөрес эшләдем, энем, килгәнең өчен рәхмәт, ләкин мин үз фикеремдә калам». Бу ике чишелешнең берсен дә кирәк санамыйм. Пьесада барган вакыйгалар – бер әйбер, ә аларның бүген ничек яңгыравы – аерым мәсьәлә. Аның бүгенге яңгырашы – Сәфәргалинең сүзләрендә. Алар буталмаган, алар ахыргы сүзләрен әйтеп ялгышкан. Ахырдан да соңгы сүзне әйтеп бетерү кирәк түгел иде. Монда бит бу ак, бу кара, Сәфәргали – молодец, Муллагали – әшәке кеше, дип әйтә торган түгел», – диде бу хакта «Сәфәр»нең авторы.

Юл. Һәм, гомумән, спектакльдәге хәрәкәткә дә аерым тукталырга кирәктер. Биредә геройлар артык хәрәкәтләнми, күбесенчә сөйләшәләр, юк, әйткәләшәләр. Бары тик яңа гына йөрәк авыруыннан коляскага утырган Сәфәргали карт мотоблогына атланып, 980 чакрымлы юлга чыгып китә. Ә «тегеләр» аны озата кала. Карт ерак китә алмый. Әле артка, әле алга таба чайкала да чайкала ул. Аны гел нәрсә яки кем дә булса туктатып кына тора. Шулай бер урында таптанганнан соң, кинәт кенә Башкортстанга килеп чыга ул. «Спектакль сәхнәнең берничә өлешендә бара. Бер урынга утырып, Сәфәргали карт әүвәлгесен искә ала, хәзерге вакыйгалар сәхнәнең бүтән өлешендә бара. Картның юлын берничә кат кисмәкче дә булалар. Гомумән, «юл» сүзенә һәм пьесага нинди мәгънә салынганын белә торып, мин аны бер урында таптану дип әйтә алмыйм», – дип аңлатты Альберт Шакиров.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

Белми калмагыз!

«ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН»ГА ЯЗЫЛУЧЫГА – МИНИ-ТРАКТОР

БҮЛӘКНЕ АЛУ ШАРТЛАРЫ

1 2022 елның беренче яртыеллыгына 6 айга «Ватаным Татарстан» газетасына язылырга.

2 «Ватаным Татарстан»ның «ВКонтакте» төркеменә язылырга һәм мини-трактор уйнату турындагы хәбәргә репост ясарга. Яки «ВТ»ның «Инстаграм» сәхифәсенә язылырга, бәйге турында «Актуаль»дәге соңгы постны скриншот ясап, «ВТ»ның аккаунтын билгеләп, үзеңә урнаштырырга.

3 Язылу квитанциясен һәм «Инстаграм» яки «ВКонтакте» аккаунтыгызның сылтамасын безгә җибәрергә: «Ватсап» (89179270040) яки почта аша (420097, Казан шәһәре, Академия урамы, 2 нче йорт, «ВТ» газетасы редакциясе), яки электрон адреска (info@vatantat.ru).

БЕЛЕШМӘЛӘР ӨЧЕН ТЕЛЕФОН: 8-917-927-00-40

Җиңүче җирәбә юлы белән ачыкланачак. Квитанцияләр 2022 елның 16 гыйнварына кадәр кабул ителә, җирәбә 20 гыйнвар көнне үткәреләчәк.

Акцияне оештыручы: «Ватаным Татарстан» газетасы ДБУ, акцияне уздыру вакыты 2021 елның 1 ноябреннән 2022 елның 15 февраленә кадәр. Тулырак мәгълүмат vatantat.ru сайтында.

УРАЛЕЦ ТОРГОВЫЙ ДОМ МЫ ПРОДАЁМ НАДЁЖНОСТЬ

АКЦИЯНЕҢ ИГАНӘЧЕСЕ – «УРАЛЕЦ» СӘҮДӘ ЙОРТЫ

✓ мини-тракторлар;
✓ барлык төр тракторлар өчен запас частьлар;
✓ җир эшкәртү, чәчү, җыйнау өчен асылмалы җиһазлар.

Казан ш., Мамадыш тракты, 35А; Чаллы ш., Казан проспекты, 252/1; Әлмәт ш., Советская урамы, 42А.

ТЕЛЕФОННАР: 8-927-465-12-94, 8-987-931-55-50

ГАЗЕТАГА ЯЗЫЛУ ЫСУЛЛАРЫ



1 ПОЧТА БҮЛЕКЧӘЛӘРЕНДӘ

2 ОНЛАЙН: vatantat.ru сайтындагы сылтама аша газетага язылу бик уңайлы һәм тиз. Программа үзе адымлап алып бара.

Әлеге QR-код ярдәмендә телефон аша газетага язылырга һәм акча түләргә мөмкин.

2022 елның беренче яртыеллыгы өчен 6 айга язылу бәяләре

П2435 атнага бер, җомга килә – 465 сум

П2409 Сишәмбе, чәршәмбе, җомга, шимбә килә – 1000,92 сум

Реклама 16+

БОЛАЙ УК КИРӘКМӘС ИДЕ

Спорт

«Бездә кризис булмады». 5 матч рәттән җиңү яулый алмый интеккән командасы Казанда ЦСКАны откач, баш тренер Леонид Слуцкий әнә шулай дигән иде. Җиңүдән баш әйләнеп, команда турнир таблицасында өскәрәк күтәрелгәч, ышандырды ул сүзләр. Тик бер атна узгач, «Рубин» Ростовта 5 туп керттерде. Монысы Слуцкий Казанда эшләгән чорда иң зур исәп белән җиңелү булды. Баш тренер уенчыларында осталык һәм характер ныклыгы җитмәвен әйтте.

	команда	очко
1	Зенит	30
2	Сочи	27
3	Динамо	26
4	Локомотив	25
5	ЦСКА	23
6	Крылья Советов	22
7	Краснодар	21
8	Рубин	19
9	Спартак	19
10	Ахмат	18
11	Ростов	16
12	Уфа	14
13	Н. Новгород	14
14	Арсенал	13
15	Химки	12
16	Урал	11

Әбит Ростовтагы уен «Рубин» уенчылары өчен бик уңышлы башланган иде. Казан командасы беренче таймда ук исәпне ачты. Шуннан соң да көндәш капкага һөҗүм оештырудан туктамадылар. Тик кунаклар булган мөмкинлектән файдаланмады. Хуҗаларның исә һәр һөҗүме диярлек гол белән тәмамланды. Алар тәнәфескә кадәр үк исәпне тигезләде. Ә икенче таймның башы «Рубин» өчен чын мәхшәргә әверелде. «Ростов» уенчылары 15 минут эчендә Казан командасы капкасына 3 туп кертте. Ахырда исә тагын берне өстәп, исәпне үз файдаларына 5:1 ясады.

Әле күптән түгел генә турнир таблицасының аскы өлешеннән күтәрелә алмаган, быел инде өченче тренер, сүз уңаеннан, озак еллар Казанда эшләп киткән Виталий Кафанов җитәкчелегендә чыгыш ясаучы «Ростов» уенчыларының тырышлыгы нәтиҗәсе генә түгел бу. «Рубин» сакчыларының авыр вакытта ни эшләргә белми аптырап калулары аркасында. Капкачы Юрий Дюпинның да соңгы очрашулардагы начар уенын китереп кушкач, Леонид Слуцкий танырга теләмәгән кризис килеп чыга.

– Нәрсә дип әйтергә дә белмим. Барысы да безнең кулда булып тоелды. Башта туп керттек, аннары Кварацхелия менә дигән тагын бер мөмкинлекне кулдан ычкындырды. Беренче тайм 2:0 исәбе белән безнең файдага төгәлләнергә тиеш иде, – диде Леонид Слуцкий очрашудан соң. – Икенче таймда исә тупас хаталар аркасында ике туп керттергәч, нидер эшләү мөмкинлеге калмады. Минем өчен бик сәер матч бу. Зур исәп белән җиңелүләр элек тә булды. Әмма бу иң сәер уеннарның берсе иде.

«Рубин»ның 14 очрашудан соң 19 очкосы бар. 5 җиңү, 4 ничья һәм 5 җиңелү. Ике атналык тәнәфестән соң Казан командасы «Сочи» белән очраша. Ә бу команда турнир таблицасында икенче урында урнашкан. Аннары өченче урындагы «Динамо», һәр очконың кадерен белүче «Нижний Новгород», үҗәт «Крылья Советов»ка каршы матчлар көтә. Кыскасы, кышкы 4 очрашуның берсе дә җиңел булмаячак. Имгәнгән уенчылар сихәтләнеп, «Рубин»га көч бирсә генә инде. Ә алар Казанда бик күп.

> «Ак барс» һөҗүмчесе Джордан Уил «Автомобилист» капкасына берьюлы 4 алка кертте. Моңа кадәр Казан командасы уенчылары КХЛда бер тапкыр гына мондый нәтиҗә күрсәтә алган. 2009 елның 29 октябрендә Алексей Морозов «Сибирь» капкасына 4 алка керткән һәм моны бер период эчендә булдырган. Ә Уилга килгәндә, Казан командасында иң күп хезмәт хакы алучы Канада хоккейчысы алдагы 17 очрашуда нибары бер мәртәбә генә уңышка ирешкән иде.

Илнар ХӨСНУЛЛИН

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар: ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 7404 данә
Гомуми тираж – 17211 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 362

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-73, 222-09-67 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы
222-09-67 – фән һәм мәгариф
222-09-64 – әдәбият, сәясәт һәм дин
222-09-66 – информация, спорт, тәрҗемә, оператор
222-09-67 – хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+